**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы | № 73 | "15" декабрь, 2022 ел

Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия ФНСның 2019 елның 2 апрелендәге ММВ-7-8/164@ "Бурычларны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны өзү тәртибен һәм түләтүгә өметсез дип танылган документлар исемлеген раслау турында" боерыгы нигезендә

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммасы өлешендә (алга таба - бурыч) бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләрне билгеләргә:

- мирас алучы мираска хокуктан баш тарткан очракта, мирас алучы булмаган яисә мирас калдырган көннән алып бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта вафат яисә вафат дип игълан ителгән физик затларның җир салымы һәм милек салымы буенча;

- җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча өч елдан артык бурычны түләтүгә өметсез дип таныган датадан;

- җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законның 46 һәм 47 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән нигезләрдә башкарма производствоны төгәлләү турында суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгарылган очракта;

- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча, реструктуризация режимында һәм бөлгенлек (банкротлык) процедураларында булган салым түләүчеләргә бурычлардан тыш;

- ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче балигъ булмаганнарның җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча;

- ЕГРЮЛда мәгълүмат булмаган юридик затларның җир салымы буенча;

- җир салымы буенча юридик затларның аларны түләтү срогы тәмамланганнан соң недоимкага исәпләнгән пенялар буенча бурычлары, алар исәпләгән недоимка булмаганда.

2. Салым түләүченең бурычы исемлеге салым органы тарафыннан әлеге карар нигезендә һәм җирле салымнар суммалары өлешендә салым органы белешмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Бурычлары түләтүгә өметсез дип танылырга тиешле физик затлар исемлеге, җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләп бетерүгә ышанычсыз дип тануның шартларын раслаучы документлар кушып, салым органы тарафыннан Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетына килештерү өчен бирелә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2014 елның 24 ноябрендәге 123 номерлы « Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында»;

- 2015 елның 5 ноябрендәге 14 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 123 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында»;

- 2018 елның 17 апрелендәге 92 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 123 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 5 ноябрендәге 14 номерлы карар редакциясендә)».

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://aznakayevo. tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина